Бажуковский филиал  Муниципальное автономное общеобразовательное учреждение

«Усть – Туркская средняя общеобразовательная школа»

| | | |
|---|---|---|
| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
| Руководитель ШМО | Заместитель директора по УВР | Директор МАОУ «Усть-Туркская СОШ» |
| ______/Муртазина | ______/ Аитова Э.Р. | ______/ Юсупова И.Ф. |
| Протокол №1 от «31» августа 2023 г. | «31» августа 2023 г. | Приказ №100 от «31» августа 2023 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА
# ПО РОДНОМУ ЯЗЫКУ
# ДЛЯ ОБУЧАЮЩИХСЯ 9 КЛАССА
# С УМСТВЕННОЙ ОТСТАЛОСТЬЮ

Составитель :

учитель татарского языка и литературы

Шавалиева З.А

## Аңлатма язуы

9нчы сыйныфлар өчен татар теленнән эш программасы түбәндәге хокукый-норматив документларга нигезләнеп төзелде:
1) Программа разработана на основе следующих нормативно-правовых документов:
Конституция Российской Федерации;
2) Федеральный закон от 29 декабря 2012 г. № 273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации» (с изменениями и дополнениями);
3)Закон Российской Федерации от 25 октября 1991 г. № 1807-1 «О языках народов Российской Федерации» (с изменениями и дополнениями);
4) Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования (утвержденный приказом Министерства просвещения Российской Федерации от 31 мая 2021 г. № 287);
5) Примерная основная образовательная программа основного общего образования (одобренная решением федерального учебно-методического объединения по общему образованию, протокол № 1/22 от 18 марта 2022 г.);
6) Примерная программа (одобрена решением федерального учебно-методического объединения по общему образованию, протокол № 2/220 от 2 июня 2020 г.);
7) Концепция преподавания родных языков народов России (утверждена решением коллегии министерства просвещения РФ от 1 октября 2019 года № ПК-3ВН).
Дәреслек: Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 9нчы с-ф. /Р.К.Сәгъдиева, Э.Х.Кадирова-Казан: "Мәгариф-Вакыт" нәшр., 2017. –243б.

Эш программасы федераль дәүләт белем бирү стандартларының минимумы таләпләренә туры килә.
Программа 17 сәгатькә исәпләнгән, татар теле атнага 0,5 сәгать өйрәнелә.
Рус мәктәпләренең 9 нчы сыйныфында укучы татар балаларына татар теленнән белем бирүнең ***төп максаты*** – Федераль дәүләт стандарты таләпләрен тормышка ашыру белән бергә рус мәктәбендә татар теленә өйрәткәндә, укучыларда лингвистик (тел), коммуникатив (аралашу), милли мәдәният өлкәсенә караган культурологик (мәдәниятлылык) компетенцияләр булдыру.
**Лингвистик компетенция.** (укучыларның ана теленнән мәгълүматлылык) фонемалар, морфемалар, сүз ясалышы, җөмләләр, җөмлә кисәкләре, лексик һәм грамматик билгеләр, лингвистик анализ.
**Коммуникатив (аралашу) компетенциясе.** Башкалар әйткәнне аңлау һәм үз фикереңне белдерү өчен тупланган белем, осталык, күнекмәләр җыелмасы; хәзерге татар теле нормаларына ия булу,сүз байлыгын, сөйләмнең грамматик ягын дөрес итеп үзләштерү; телдән һәм язма формада бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен булдыру

**Культурологик (мәдәниятлылык) компетенция.** Телне милли-мәдәни яссылыкта үзләштерү. Укучыларны сөйләмгә өйрәткәндә, рухи, эстетик тәрбия һәм белем бирү чарасы буларак, милли үзенчәлекләрне чагылдырган текстлар белән эшләү, тормыш-көнкүреш, гореф-гадәт үзенчәлекләрен, сынлы сәнгать әсәрләрен,
халык авыз иҗаты үрнәкләрен белү, татар сөйләм этикетына ия булу.

**Төп бурычлар:**

1. Телне өйрәнүгә карата башлангыч сыйныфларда нигез салынган кызыксынуны көчәйтү, үз милләтеңә, телеңә хөрмәт белән карау, шулай ук татар теле аша башка милләт вәкилләренә, аларның рухи мирасына мәхәббәт хисе тәрбияләү.
2. Татар теленең барлык бүлекләре буенча эзлекле рәвештә фәнни белем бирү.
3. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру. Туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү.
4. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү. Көндәлек тормышта татар теле мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана белергә өйрәтү.
5. Туган тел ярдәмендә өзлексез белем һәм тәҗрибә туплау.
6. Татар телен башка фәннәр буенча белем алу чарасы буларак кулланырга өйрәтү күнекмәләре булдыру.
7. Укучыларны даими рәвештә татар милли мәдәнияты мирасына тарту.
8. Татар теле дәресләрендә белем бирү белән бергә тәрбияви бурычны да онытмау. Телебезнең тәрбияви мөмкинлекләрен ачуда укуга карата кызыксыну уяту.

Изложение һәм сочинениеләрне дә тәрбияви бурычны күз уңында тотып яздыру.

9. Укучыларның логик фикерләү дәрәҗәсен үстерү. Аралашканда, фикерләрне ачык, аңлаешлы, эзлекле, стилистик яктан дөрес, төгәл итеп белдерү.

Укучыларда ана телендә дөрес, матур итеп сөйләү һәм язу күнекмәләре тәрбияләү.

10. Дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү.

**Татар теле укытуның максатлары һәм бурычлары:**

Укучыларда татар теленә хөрмәт һәм аны ярату, рухи кыйммәт һәм кешелек дөньясының аралашу, белем алу чарасы буларак аңлы караш тәрбияләү;

Укучыларның сөйләү һәм фикерләү сәләтен үстерү, аларны татар әдәби телен тормышның төрле өлкәләрендә ирекле куллана алырлык шәхесләр итеп тәрбияләү; дөрес сөйләм эшчәнлегенең үзара аралашу чарасы икәнен белдерү;

Татар теле, аның төзелеше, кулланылышы турында мәгълүмат алу; татар әдәби теленең төп нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллау, аларны тиешенчә куллана белү; сүз байлыгын арттыру, сөйләмдә кулланыла торган грамматик чараларны төрлеләндерү;

Телне өйрәнгәндә үзләштергән белем һәм күнекмәләрне сөйләмдә дөрес куллана белү.

| № | **Төп темалар** | **Белем һәм күнекмәләр** |
|---|---|---|
| 1 | Гади җөмлә синтаксисы; | Синтаксис буенча өйрәнгәннәрне искә төшерү. |
| 2 | Кушма җөмлә синтаксисыы һәм пунктуация | -Кушма җөмлә: кушма җөмлә турында гомуми төшенчә, кушма җөмлә төзүче җөмләләрнең бер-берсенә бәйләнеше.<br><br>-Тезмә кушма җөмлә: тезмә кушма җөмләләрдә бәйләүче чаралар; теркәгечле тезмә кушма җөмләләр, алар янында тыныш билгеләре; теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр, алар янында тыныш биогеләре.<br><br>-Иярченле кушма җөмлә: баш һәм иярчен җөмлә; иярчен җөмләләрне мәгънә һәм төзелеш ягыннан төркемләү.<br><br>-Иярченле кушма җөмләнең төзелеш ягыннан төрләре: аналитик иярчен җөмләләр, синтетик иярчен җөмләләр, иярченле кушма җөмләләрнең синонимлыгы һәм рус телендә бирелеш формалары;<br><br>-Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре: иярчен ия җөмлә, иярчен хәбәр җөмлә, иярчен тәмамлык җөмлә, иярчен аергыч җөмлә;<br><br>-Иярчен хәл җөмләләр: иярчен вакыт җөмлә, иярчен урын җөмлә, иярчен рәвеш җөмлә, иярчен күләм җөмлә, иярчен максат җөмлә, иярчен шарт җөмлә, иярчен кире җөмлә, иярчен кереш җөмлә,;мәгънә һәм төзелеше ягыннан төрле булган иярченле кушма җөмләләрне сөйләмдә дөрес куллану, иярченле кушма җөмләләрне үзгәртеп кору; |

| | | |
|---|---|---|
| | | -Катлаулы кушма җөмләләр: күп тезмәле кушма җөмлә, күп иярченле кушма җөмләләр, тиңдәш, тиңдәш түгел бер-бер артлы ияртүле һәм берничә төр ияртүле күп иярченле кушма җөмләләр; катнаш кушма җөмләләр турында төшенчә; |
| 3 | Текст синтаксисы һәм пунктуация | -Текст синтаксисы: туры һәм кыек сөйләм, туры сөйләм янында тыныш билгеләре; |
| 4 | Стилистика һәи сөйләм культурасы | -Әдәби һәм язма сөйләм стильләре турында төшенчә; язма сөйләм стильләре; синонимнарның сөйләм оештырудагы роле, стилистик хаталар; сөйләм культурасы, әдәби тел нормалары; |
| 5 | 5 – 9 нчы сыйныфларда үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау | -Фонетика, орфоэпия, графика һәм орфография; лексикология;сүз төзелеше һәм сүз ясалышы; морфология, синтаксис һәм пунктуация |

**Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы:**

- **Коммуникатив компетенция.** Сөйләм. Телдән һәм язма сөйләм. Диалогик һәм монологик сөйләм. Сөйләм стильләре. Матур әдәбият теле.
- Телдән һәм язма сөйләмне аеру. Тел берәмлекләрен аралашуны ситуация үзенчәлекләренә карап сайлый белү. Аралашу өлкәсенә һәм ситуациясенә бәйле рәвештә телдән һәм язма сөйләмне дөрес файдалану.
- Текстның темасы, төп фикере һәм төзелеше. Аларның стильләрендә жанр төрлелеге.
- Татар әдәби теле һәм аның нормалары турында төшенчә.
- Сөйләм эшчәнлеге төрләрен (тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм язу) үзләштерү.
- Укуның төрле төрләрен (танышу, өйрәнү һ.б.) үзләштерү. Уку китаплары, массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет һ.б. чаралар белән эшләү алымнарын үзләштерү.

- Иҗтимагый-мәдәни, әхлакый, көнкүреш, уку темаларына бәйле булган монологик һәм диалогик сөйләм үрнәкләрен төзү.
- Текстның эчтәлеген кыскача , тулы яки сайлап алып сөйләү. Диктантлар, изложениеләр һәм сочинениеләр язу. Төрле стиль һәм жанрдагы текстлар төзү: бәяләмә, аннотация, хат, ышаныч кәгазе, гариза, тезис, конспект һ.б.ш.
- **Лингвистик компетенция**. Телнең кеше тормышында һәм җәмгыятьтә тоткан урыны. Татар теле – Татарстан Республикасының дәүләт теле. Татар теле – татар халкының милли теле.
- Матур әдәбият һәм аның нормалары турында төшенчә.
- Татар теленең үсештә булуы. Соңгы елларда татар теле лексикасындагы үзгәрешләр.
- Тел белеменә караган сүзлекләр һәм алардан файдалану.

**Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:**

- ана теленең төп берәмлекләрен һәм аларның билгеләрен белү;
- телдән һәм язма сөйләм, диалог, монолог, аралашу ситуацияләрендә тел стильләре, текст төшенчәләрен аңлау һәм гамәлдә дөрес куллану;
- тыңлап аңлау һәм уку буенча телдән һәм язма рәвештә (радио, телеведениедән һ.б.) хәбәр ителгән мәгълүматны аңлау;
- сөйләү һәм язуда татар әдәби теленең төп нормаларын (орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик һәм пунктацион) саклау һәм сөйләм әхлагы нормаларын үтәү;
- татар теленең фонетик, лексик системаларын һәм грамматик төзелешен үзләштерү;
- сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерә белү;
- текст төзелешен һәм тел үзенчәлекләрен билгели белү;
- сөйләм стиле, фәнни, публицистик, рәсми-эш, матур әдәбият стильләрен аерырга өйрәтү;
- ана теленең грамматик категорияләрен белү;
- грамматик үзенчәлекләренә карап, сүз төркемнәрен аера белү;
- сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау;
- сүз, сүзтезмә, җөмләләрдәге хаталарны төзәтү;
- җөмләгә синтаксик анализ ясау;
- төрле стиль һәм жанрдагы текстларны тиешенчә уку күнекмәләре булдыру;
- төрле сүзлекләрдән һәм белешмә характерындагы китаплардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан урынлы файдалану;
- синтетик һәм аналитик иярченле кушма җөмләләрне сөйләмдә куллана белү;
- текстның эчтәлеген телдән яки язмача төгәл итеп, сайлап яки кыскача, гади һәм кушма җөмләләр кулланып сөйли белү;

- бирелгән темага, куелган максатка ярашлы рәвештә, төрле ситуацияләрдән чыгып, сурәтләү яки хикәяләү характерындагы текстларны телдән яки язмача әзерләү;
- җөмләнең тиңдәш кисәкләрен, аерымланган кисәкләрен тиешенчә куллана белү, алар янында тыныш билгеләрен кую;
- сорауларга тулы һәм дөрес итеп җавап бирү;
- төрмыш-көнкүреш, уку, иҗтимагый, мәдәни темаларга әңгәмә кору, үз фикереңне яклап, әңгәмә-бәхәс формасында сөйләшү күнекмәләренә ия булу”
- туры һәм кыек сөйләмнән урынлы файдалану, алар янына тиешле тыныш билгеләрен кую;
- текстның планын төзү яки аның эчтәлеген конспект формасында язу;
- тәкъдим ителгән текстларны рус теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү;
- ана теленең башка фәннәрне өйрәнү һәм белем алу чарасы икәнен аңлау;
- татар теле дәресләрендә алган белем һәм күнекмәләрне ана теленең кеше һәм җәмгыять тормышында алып торган урынын аңлап куллана һәм бәяли белергә өйрәнү, татар теленең Татарстан Республикасында дәүләт теле буларак өйрәнелүен, аның иҗтимагый әһәмиятенең артуын аңлау.

## Календарь-тематик план

| № | Дәрес темасы | Үтәлү вакыты | | Сәгать | Көтелгән нәтиҗә | | | Өй эше |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | план | факт | | Махсус белем | Махсус күнекмә | Гомумуку күнекмәләре | |
| 1 | Гади җөмлә синтаксисын кабатлау | | | 1 | Үткәннәрне кабатлау | Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрен, җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен, тиңдәш кисәкләрне, аерымланган кисәкләре, модаль кисәкләре һәм алар янында тыныш билгеләренең куелышын искә төшерү | 8нче сыйныфта үткәннәрне ныгыту | 8 нче күнегүне язып эшләргә |
| 2 | Контроль күчереп язу | | | 1 | Үткәннәрне гомумиләште реп кабатлау<br>. | Алган белемнәрне гамәлдә куллану күнекмәләрен камилләштерә алу. Җөмлә төрләрен дөрес билгеләп, тыныш билгесен дөрес кую. | Язма эшне дөрес итеп башкару, биремнәрне төгәл итеп үтәү | “Курайчы” картинасы буенча сөйләргә өйрәнергә |
| 3 | Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр | | | 1 | Теркәгечле тезмә кушма җөмләләр, аларның аерым компонентлары арасындагы мәгънәви бәйләнешләр. Тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре. | Тезмә кушма җөмләләр синонимлыгыннан файдалана белү. | Синтаксик анализ ясый белү | Схемага туры китереп, җөмләләр уйлап язарга |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Иярченле кушма җөмләләр, синтетик һәм аналитик иярчен җөмләләрнең үзенчәлекләре | | | 1 | Иярченле кушма җөмләләр турында мәгълүмат. Үзара иярт ү юлы белән бәйләнгән җөмләләрнең иярченле кушма җөмлә дип аталуы. Баш һәм иярчен җөмләләр. | Иярченле кушма җөмләләрнең кулланылышын сөйләмдә камилләштерү | Дөрес һәм төгәл җавап бирүне камилләштерү | 57 нче күнегүне язып эшләргә |
| 5 | Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре. Иярчен ия җөмлә, иярчен хәбәр җөмлә. | | | 1 | Иярчен ия җөмләнең баш җөмләнең иясе урынында килүе,тыныш билгеләренең куелышы | Аларның функцияләре. Төзелеш ягыннан төрләре. | Чагыштыру, нәтиҗә ясау күнекмәләрен үстерү | 77 нче күнегүне язып эшләргә |
| 6 | Иярчен тәмамлык җөмлә. | | | 1 | Иярчен тәмамлык җөмләнең баш җөмләнең тәмамлыгы урынында килүе, тыныш билгеләренең куелышы | Иярчен җөмләләрнең аналитик һәм синтетик төре дә булуы | Рус җөмләләре белән охшаш һәм аермалы яклары | 83 нче күнегүне язып эшләргә |
| 7 | Иярчен аергыч җөмлә. | | | 1 | Иярчен аергыч җөмләнең баш җөмләнең аергычы урынында килүе,тыныш билгеләренең куелышы | Иярчен аергыч җөмләнең я баш җөмләнең аергычы урынында килүе, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән аергычны ачыклавы; аналитик һәм синтетик төрләре булуы | Иярчен хәбәр һәм иярчен аергыч җөмләләр арасында уртак һәм аермалыклы яклар | 89 нчы күнегүне язып эшләргә |
| 8 | Иярчен вакыт җөмлә. | | | 1 | Иярчен вакыт | Иярчен вакыт җөмләнең я | Иярчен вакыт | 101 нче күнегүне |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Күрмә диктант | | | | җөмләнең аналитик һәм синтетик төре булуы | баш җөмләнең вакыт хәле урынында килүе, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән вакыт хәлен ачыклавы; аналитик и. ж. баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә, синтетик и.ж. баш җөмләгә кайбер килеш һәм хәл фигыль кушымчалары ярдәмендә бәйләнүе. | җөмләнең синонимик вариантларын төзү | язып эшләргә |
| 9 | Иярчен урын җөмлә. | | | 1 | Иярчен урын җөмләнең күбрәк аналитик төре, сирәгрәк синтетик төре булуы, тыныш билгеләренең куелышы. | Аналитик җөмләнең баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүз ярдәмендә бәйләнүе. | Иярчен урын җөмләләрне башка иярчен җөмләләрдән аерырга өйрәнү | 101 нче күнегүне язып эшләргә |
| 10 | Иярчен рәвеш җөмлә. | | | 1 | Иярчен рәвеш җөмләләрнең аналитик һәм синтетик төре, тыныш билгеләренең куелышы | Тыныш билгеләрен дөрес кую | Предметара бәйләнеш | 106 нчы күнеүне язып эшләргә, синтаксик анализ ясарга |
| 11 | Иярчен күләм җөмлә. | | | 1 | Иярчен күләм җөмләләрнең аналитик һәм синтетик төре, тыныш билгеләренең куелышы | Бәйләүче чараларны дөрес билгеләү | Мәгънә һәм төзелеше ягыннан төрле булган иярченле кушма җөмләләрне сөйләмдә дөрес куллану | 111нче күнегүне язып эшләргә |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12 | Иярчен сәбәп җөмлә.<br>Тест эшләү | | | 1 | Иярчен сәбәп җөмләнең баш җөмләнең сәбәп хәле урынында килүе, тыныш билгеләренең куелышы. | Синтаксик анализ ясый белү. | Рус теле белән чагыштыру | Кагыйдәне өйрәнергә, 116 нчы күнегүне язып эшләргә |
| 13 | Иярчен максат җөмлә. | | | 1 | Иярчен максат җөмләнең аналитик һәм синтетик төре булуы,тыныш билгеләренең куелышы. | Мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү | Иярчен сәбәп һәм иярчен максат җөмләләр арасында аермалы якларны өйрәнү | 121 нче күнегүне язып эшләргә |
| 14 | Иярчен шарт җөмлә.<br>Аңлатмалы диктант | | | 1 | Шарт хәлен ачыклавы, нишләсә ? ни булса ? кебек сорауларга җавап бирүе, тыныш билгеләренең куелышы. | Дәреслек белән эшли белү. | Биремнәрне үтәгәндә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү | 130-131 нче күнегүләрне язып эшләргә |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 15 | Иярчен кире җөмлә. | | | 1 | Иярчен кире җөмлә баш җөмләнең кире хәле урынында килүе, тыныш билгеләренең куелышы | Дәреслек белән эшли белү | Биремнәрне үтәгәндә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү | 138 нче күнегүне язып эшләргә |
| 16 | А.А.Пластовның “Чишмә” картинасы буенча сөйләү | | | 1 | Бирелгән картина буенча хикәяләү төрендәге сочинение язуның таләпләрен искә төшерү. | Теманы тулы һәм эзлекле итеп ача алу осталыгы | Иҗади күзаллау сәләтен камилләштерү | Үткәннәрне кабатларга |
| 17 | Кабатлау. Уку елына йомгак | | | 1 | Белемнәрне гомумиләштереп кабатлау | Алган белем һәм күнекмәләрне тормышта урынлы куллана белү | Үз-үзеңне дөрес бәяләү күнекмәсен камилләштерү | Кагыйдәләрне кабатлап чыгарга |